Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Иске Роман авыл җирлеге Советы карары

2026 елның 29 апреленнән №10/1

«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмә хакында» 2022 елның 29 апрелендәге 21/2 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Иске Роман авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Бу нигездә

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 567-ФЗ номерлы Федераль закон белән, федераль законнарны бозуларны бетерү турында Чистай шәһәр прокурорының 2026 елның 24 мартындагы 02-08-03-2026 номерлы тәкъдимен карап, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Кертергә

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмә хакында» 2022 елның 29 апрелендәге 21/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмә түбәндәге үзгәрешләр:

1.1. 4.7.1 пунктның 3 абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:
«Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында тикшереп торучы затка ул башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча 284-ФЗ номерлы Законның 21 маддәсендәге 5 өлешендә каралган тәртиптә хәбәр ителә»;

1.2. 4.7.2 пунктның 5 абзацына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:
«5) контрольдә тотылучы зат әлеге пунктның 2 абзацында каралган критерийларга туры килми.»;

1.3. 5.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5.5. Әгәр муниципаль контроль органы вазыйфаи заты карамагында булган белешмәләр һәм документлар җитәрлек булмаса, документлар буенча тикшерү барышында түбәндәге Контроль (күзәтчелек) гамәлләр башкарылырга мөмкин:».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә чикләнмәгән даирә затлары өчен уңайлы урыннарда урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштырырга, шулай ук Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Иске Роман авыл җирлеге
башлыгы Р. Г. Дәүләтшина